# Тамчы

**Школьная газета МБОУ «Джалильская СОШ №2»**

**«2 нче санлы Җәлил урта мәктәбе» газетасы**

апрель **№8** (68) 2016-2017 нче уку елы


## РЕДАКТОР СҮЗЕ

Илдә кояш,
Җирдә кояш,
Йөздә кояш, күздә кояш,
Әмма бүген үзгә кояш.
Бүген аның каршысына
Канатланып чыккан бөре...
Аваз сала томшыклары:
Тукай көне!
Тукай көне!
Киләә язлар, китә язлар,
Һәр ел саен үзгәрелә...
Үзгәрелә...
Һәр ел саен Тукай гына
Япь-яшь хәлдә килә безгә.
Киңлекләрдә язгы аваз –
Чыр-чу килә кошлар иле,
Чеңләп тора аһәңнәре:
Тукай көне!
Тукай көне!
Илдә кояш,
Жирдә кояш,
Тукай көне канат җәйгән.
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,
Тукай көне –
Безнең бәйрәм!

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ

### Яздан аерып булмый Тукайны...

Шагыйрь хаклы. Айлар, еллар үтәр. Гасырларны гасырлар алыштырыр. Татар теле яшәгәндә, Тукай югалмас, үлмәс, онытылмас. Онытылырга тиеш түгел, онытырга хакыбыз юк. Быел без бөек шагыйребезнең 131 еллыгын билгеләп үтәбез. Аның туган көне уңаеннан апрель аен “Тукай айлыгы” дип игълан иттек. Айлыкны 4 атналыкка бүлдек.Беренчесе – “Китап – белем чишмәсе” атналыгы.. Ул галиҗәнап китапка багышланачак. Икенче атнада халкыбызның күңел җәүһәрләрен өйрәнергә, пропагандаларга җыенабыз. Өченче атна — экология атнасы. 2017 нче ел Россиядә “Экология елы” дип игълан ителде. Айлыкның соңгы атнасы бөек шагыйребез иҗатына, аның тормышы һәм шигъриятенә багышланачак.

Эшчәнлекнең планы төзелде, юнәлешләр билгеләнде. Инде җиң сызганып эшкә керешик. “Тамчы” газетасы битләрендә атналыклар турында тулы мәгълүмат бирелеп барачак. Сездән активлык кына көтелә.

Хәерле сәгатьтә! Хуш киләсең, Тукай язы!

**Ландыш Камил кызы Шәйдуллина**

### «КИТАП БЕЛЕМ ЧИШМӘСЕ» АТНАЛЫГЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Айлыкның беренче атнасы кешелек уйлап тапкан иң зур могҗиза – китапка багышланды. Ул китапханә дәресләре белән башланып китте. Дәресләрне Җәлил балалар китапханәсе китапханәчеләре Фәния Нуриева һәм Зилә Садыйкова, мәктәбебез китапханәчесе Алина Зиннәтуллиналар оештырды. Укучылар китап йортларында кунакта булдылар. Китапханәчеләр үзләре дә укучылар янына кунакка килделәр.

Чәршәмбе көнне “Укымый калма” дип аталган сораштыру уткәрелде. Мәктәпкә керү белән укытучылар да, укучылар да, үзләренең яраткан әсәрләренең исемен язып, язмаларын элмә тактага урнаштырдылар. Нәтиҗә: Г.Тукай, М.Җәлил, Р.Миңнуллин шигырьләре, З.Кадырова әсәрләре, Г.Әпсәләмовның легендар “Ак чәчәкләре” – иң яратканнары икән!

Ч.К.Шәйдуллина оештырган әдәби викторина укучыларның татар әдәбиятын белүләренә сынау булды. 5нчеләр дә, 6нчы сыйныф укучылары да сынатмадылар.

2,3 нчеләр арасында булган бәйге “Иң грамоталы укучы”ны билгеләргә ярдәм итте. 2 нчеләр арасында бу исемгә Салихова Сөмбел (2 б), Арсланова Камилә (2 б), Галиева Назилә (2 а), Кәримов Илназ (2 в), 3 нчеләрдән Нигъматуллина Наилә (3 в), Хәйретдинова Әдилә (3 а), Гәрәев Нияз (3 а), Ибраһимова Алия (3 а) лаек булды. “Иң пөхтә татар теле дәфтәре” бәйгесендә 3нче а сыйныфыннан Гәрәев Нияз, 3 нче б дан Вафина Ләйсән, 3 нче в дан Нигъматуллина Наилә җиңү яулады.

Л.М. Гаскарова тарафыннан оештырылган “Китап – белем чишмәсе” проектлар яклау бәйгесе дә нәтиҗәле булды..

6,7 нче апрель көннәрендә – “Әдәбиятта экология темасы” дигән исем астында 5,7,8 нче б сыйныф укучылары өчен тәрбия сәгатьләре үткәрелде.

Җомга көнне китап мәктәп мөгаллимнәрен “Хатирәләр яшәртә күңелне” дигән матур шигъри кичәгә дәште. Л.К..Шәйдуллина ветеран мөгаллимә Лена Габдулла кызы Юнысованың “Хатирәләр” китабын презентацияләде.

Айлыкның беренче өлеше бер атна дәвасында барган “Китап битләре буйлап” рәсем конкурсына йомгак ясау белән тәгәлләнде. Нәтиҗәләрне 10 нчы сыйныф укучыларыннан торган хөкемдарлар төркеме чыгарды.

**Айлык дәвам итә. Бәйгеләрдә катнашыашыгыгыз!**

## «КИТАП - БЕЛЕМ ЧИШМӘСЕ» АТНАЛЫГЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН















## “Китап битләре буйлап” конкурсы җиңүчеләре:

1-4 нче сыйныф укучылары арасында:




- 1 нче урын: Яббарова Диләрә (3 нче а сыйныфы) – А.Алишның “Чукмар белән Тукмар” әкияте буенча рәсеме өчен;
- 2 нче урын: Байбекова Аида (1 нче в сыйныфы) – Г.Тукайның “Су анасы” әкияте буенча рәсеме өчен;
- 2 нче урын: Баяндин Антон (3 нче в сыйныфы) – Н.Арслановның “Яз” шигыре буенча рәсеме өчен;
- 3 нче урын: Дәүләтшина Азалия (2 нче в сыйныфы) – З.Нуриның “Кошларга бүләк” шигыренә аппликациясе өчен;
- 3 нче урын: Баянова Элина (1 нче в сыйныфы) – Г.Тукайның “Эш беткәч уйнарга ярый” шигыре буенча рәсеме өчен;
- 3 нче урын: Салихова Сөмбел (4 нче б сыйныфы) – Р.Миңнуллинның “Үзем белән үзем” шигыре буенча рәсеме өчен.

5-11 нче сыйныф укучылары арасында:

- 1нче урын: Багманова Аэлита (8 нче а сыйныфы) – Г.Тукайның “Су анасы” әкияте буенча рәсеме өчен;
- 2 нче урын: Никишина Дарья (5 нче а сыйныфы), 2 нче урын: Якупова Алина (5 нче в сыйныфы) – икесенә дә Н.Дәүлинең “Бәхет кайда була” шигыре буенча рәсемнәре өчен;
- 3 нче урын: Шәйхуллова Зарина (5 нче в сыйныфы) – Р.Ахунҗанованың “Җырлы чишмә” җыентыгы макеты өчен;
- 3 нче урын: Якунин Сергей (11 нче а сыйныфы) – Г.Тукайның “Су анасы” әкияте буенча рәсеме өчен;
- 3 нче урын: Мусина Динара (7 нче б сыйныфы) – Г.Тукайның “Шүрәле” әкияте буенча рәсеме өчен.



К О Т Л Ы Й Б Ы З !

**Шеф редактор**: Шайдуллина Ландыш Камил кызы

Редколлегиядә: Зәкиева Азалия, Мөхәмәтгалиева Гүзәл, Насыйбуллин Данияр (6-в)